РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» 05 2020 ел №299

Аренда түләүләрен түләүдән
азат итү өлешендә
кече һәм урта эшкуарлык субъектларына
ярдәм чаралары турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законга, 2020 елның 19 мартындагы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында»гы 670-р санлы күрсәтмәсенә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге «Яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында иң күп зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында»гы 434 санлы карарына, 2020 елның 22 апрелендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 821-р санлы күрсәтмәсенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты **к а р а р и т ә:**

1. Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына муниципаль милекне арендага бирү (шул исәптән җир кишәрлекләре) килешүләре буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль казнасын тәшкил итүче һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләр (алга таба – муниципаль милек) белән тәэмин итәргә:

а) Россия икътисады тармакларында эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән арендаторлар-мөрәҗәгать иткән көннән алып 7 эш көне эчендә яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә килеп туган хәлнең начараюы шартларында зыян күргәннәр, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге «Яңа коронавирус йогышы таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисадының тармаклары исемлеген раслау турында» 434 санлы карары белән расланган исемлектәге мондый арендаторларны 2020 елның апрель - июнь айлары өчен муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүдән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү. Күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү,

әгәр дә аренда килешүендә, күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен, аннан файдалану максатларында, муниципаль мөлкәтне арендага бирү каралган булса, һәм күрсәтелгән эшчәнлек төрен (эшчәнлек төрләрен) гамәлгә ашыру өчен тиешле мөлкәтне куллануны раслаучы документлар булганда гамәлгә ашырыла;

б) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында арендаторлар – кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

2. Әлеге карар нигезендә күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү  - Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек режимы кертелгән яисә гадәттән тыш хәл булган кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларының муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләре түләү буенча башкарылмаган бурычлары булмаган, әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдаланылган арендаторларга карата башкарыла дип билгеләргә;

3. Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына әлеге карарның үтәлеше турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 2020 елның II кварталыннан башлап кварталдан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының https://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга,  http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе А.А. Шафигуллин

Е. С. Огнева
(85593)2-76-31